ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.07.2021г. с. Муслюмово № 293

**«Социаль түләү күләмен исәпләп чыгару өчен Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативы турында» 2021 елның 25 маендагы 214 номерлы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәреш кертү хакында**

«Социаль түләү күләмен исәпләп чыгару өчен Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативы турында» 2021 елның 25 маендагы 214 номерлы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карарын гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРДЕ:**

1. 1 нче пунктка үзгәреш кертергә һәм түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының торак шартларын яхшырту чараларын үткәрүгә социаль түләү күләмен исәпләп чыгару өчен торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясен түбәндәгечә расларга:

- Мөслим авылында 1 кв. м – 25 692 сум».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтына (https://muslumovo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Мөслим муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Т. Демидов**